ГЛАВА ОТАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октябрьская, д.17, с. Отарка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422180

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОТАРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Октябрь ур., 17 нче йорт, Отарка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422180

тел.(факс): (85563) 3-74-77; e-mail: Otar..Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

---

Карар Постановление

23.10. 2020 ел. № 3

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка» совхозы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Отарка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, “Пятилетка” совхозы поселогы,Узэк урам, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан “Пятилетка» совхозы поселогы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 18 ноябре, 15.00 сәгатьтэ Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенең “Пятилетка» совхозы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлегенен “Пятилетка” совхозы торак пункты территориясендә
яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- "Пятилетка" совхозы торак пунктында су башнясы коймасын урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) »;

- "Пятилетка” совхозы торак пунктына керү юлында чокырларны ямау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- "Пятилетка" совхозы торак пунктында урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) »;
- «Пятилетка " совхозы торак пунктында юлларны кардан чистарту»;

« ӘЙЕ » « ЮК »

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Отарка авыл җирлеге башкарма комитетына “Пятилетка” совхозы торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Отарка авыл җирлеге башлыгы: / И.И.Фазылов/